Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

14 февраль 2019 ел                                                                 № 06

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә Әлмәт муниципаль районында һәм Әлмәт шәһәрендә халык алдында тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Төзүчеләр пр-кт, 76 йорт адресы, 16:07:050112:1467 кадастр номеры булган җир кишәрлегендә рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылу, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлаулары билгеләргә.

- кишәрлекнең ян сызыгыннан корылмаларның минималь чигенеше (кадастр номеры 16:45:050112:391) җир кишәрлеге ягыннан- 6 м,

- кишәрлекнең ян сызыгыннан (кадастр номеры 16:45:050112:383 булган җир кишәрлеге ягыннан) - 9 м,

- корылмаларның арткы чиктән минималь чигенеше - 8 м, катлар - "5тән алып 10"га кадәр.

2. Определить:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 1 мартында 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары - әлеге карар басылып чыкканнан соң бер айдан да артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны-Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 39.

2.4. Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылу мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырырга:

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 1 мартына кадәр.

3. "Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы А.Р. Хайруллин